## Март аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 5.57 | 7.27 | 13.05 | 16.23 | 18.20 | 19.50 |
| 2 | 5.55 | 7.25 | 13.05 | 16.24 | 18.22 | 19.52 |
| 3 | 5.53 | 7.23 | 13.05 | 16.26 | 18.24 | 19.54 |
| 4 | 5.53 | 7.23 | 13.05 | 16.26 | 18.24 | 19.54 |
| 5 | 5.51 | 7.21 | 13.05 | 16.28 | 18.25 | 19.55 |
| 6 | 5.46 | 7.16 | 13.05 | 16.31 | 18.29 | 19.59 |
| 7 | 5.44 | 7.14 | 13.05 | 16.33 | 18.31 | 20.01 |
| 8 | 5.41 | 7.11 | 13.05 | 16.34 | 18.33 | 20.03 |
| 9 | 5.39 | 7.09 | 13.05 | 16.36 | 18.35 | 20.05 |
| 10 | 5.37 | 7.07 | 13.05 | 16.37 | 18.37 | 20.07 |
| 11 | 5.37 | 7.07 | 13.05 | 16.37 | 18.37 | 20.07 |
| 12 | 5.34 | 7.04 | 13.05 | 16.39 | 18.39 | 20.09 |
| 13 | 5.29 | 6.59 | 13.05 | 16.42 | 18.42 | 20.12 |
| 14 | 5.27 | 6.57 | 13.05 | 16.44 | 18.44 | 20.14 |
| 15 | 5.25 | 6.55 | 13.05 | 16.45 | 18.46 | 20.16 |
| 16 | 5.22 | 6.52 | 13.05 | 16.47 | 18.48 | 20.18 |
| 17 | 5.20 | 6.50 | 13.05 | 16.48 | 18.50 | 20.20 |
| 18 | 5.17 | 6.47 | 13.05 | 16.50 | 18.51 | 20.21 |
| 19 | 5.17 | 6.47 | 13.05 | 16.50 | 18.51 | 20.21 |
| 20 | 5.13 | 6.43 | 13.05 | 16.52 | 18.55 | 20.25 |
| 21 | 5.10 | 6.40 | 13.05 | 16.54 | 18.57 | 20.27 |
| 22 | 5.08 | 6.38 | 13.05 | 16.55 | 18.59 | 20.29 |
| 23 | 5.05 | 6.35 | 13.05 | 16.57 | 19.00 | 20.30 |
| 24 | 5.03 | 6.33 | 13.05 | 16.58 | 19.02 | 20.32 |
| 25 | 5.01 | 6.31 | 13.05 | 17.00 | 19.04 | 20.34 |
| 26 | 4.58 | 6.28 | 13.05 | 17.01 | 19.06 | 20.36 |
| 27 | 4.56 | 6.26 | 13.05 | 17.02 | 19.08 | 20.38 |
| 28 | 4.53 | 6.23 | 13.05 | 17.04 | 19.10 | 20.40 |
| 29 | 4.51 | 6.21 | 13.05 | 17.05 | 19.11 | 20.41 |
| 30 | 4.49 | 6.19 | 13.05 | 17.06 | 19.13 | 20.43 |
| 31 | 4.46 | 6.16 | 13.05 | 17.08 | 19.15 | 20.45 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре өзерләде, мөфти Вагыйз хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*

**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

# Кыйбла

„БЕРДӘМЛЕК" ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ

№ 2
2012 ел
февраль



*ВӘГАЗЬ*

## Тәвәккәл итү хакында

Тәвәккәл итү - Коръән-Кәримдә кешенең нинди дә булса мәсьәләдә үзенә төшкән җаваплылыкны җиренә җиткергәннән соң, ул мәсьәлә белән бәйле рәвештә Аллаһыга ышануы мәгънәсендә аңлатыла. Бу - һәртөрле ситуациядә Аңа ышану дигән сүз. Аллаһы бер яктан үзенә ышануыбызны көткәндә, икенче яктан да үзебезгә төшкән барлык җаваплылыкларны җиренә җиткерү һәм бу юнәлештә кирәкле чаралар күрүебезне тели. Халык арасында бу вәзгыять «Дөяне нык казыкка бәйлә, соңыннан тәвәккәл ит, ягъни калганын Аллаһыга тапшыр, Аңа ышан» рәвешендә аңлатыла. Ләкин шуны дөрес аңларга кирәк, тәвәккәл итү - эшләрне Аллаһыга тапшырып, кырын яту түгел, киресенчә, көчебез һәм мөмкинлекләребез җиткәнчә, кулыбыздан килгәнне башкарганнан соң, кирәкле чараларны күргәннән соң, ул эшнең нәтиҗәсен безнең өчен Аллаһы бирүенә ышану ул.

Тәвәккәл итүче кеше - ният әйтеп башлаган эшнең нәтиҗәсен Аллаһы билгеләвенә, Ул бирәчәгенә тулысынча ышанучы кеше. Түбәндәге аятьләр дә кешене Аллаһыга ышанырга чакыра:

*«Аллаһы бар нәрсәне яралтучы. Ул һәрнәрсәнең вәкиле»* (39/62).

*“Үлемсез һәм һәрвакыт тере булган Аллаһыга ышан»* (25/59).

*«Аллаһыга тәвәккәл ит. Химаяче буларак Аллаһы җитәр»* (3/33).

Мөселман кешенең догасы түбәндәгечә яңгырый: *«Моны мин фәкать Аллаһының ярдәме белән генә башкара алам. Бары тик Аңа тәвәккәл иттем, бары тик Аңа кайтачакмын»* («һуд» сүрәсе, 88 нче аять). *«Аллаһының ярдәме безгә җитәр. Ул яхшы вәкилдер»* («Гыймран» сүрәсе, 173 нче аять). Тәвәккәл итүче кеше эшкә керешү һәм аларны дәвам иттерүдә кыюлык күрсәтүче, гайрәт сарыф итүче ул. Үз гайрәтенең никадәр кыйммәтле булуын да белер. «Нәҗем» сүрәсенең 38-41 нче аятьләрендә бу вәзгыять түбәндәгечә ачыклана: *«Хактыр ки, һичбер гөнаһкяр башка кешенең гөнаһларын үз өстенә ала алмый. Белеп тор, и адәм баласы, кешегә үзе кылмышларыннан башка һичбер нәрсә йөкләнмәс. Аның кылмышларына киләчәктә бәя биреләчәк. Ахырда кылмышларына күрә әҗерен дә алачак».* Шуңа күрә эшләү, тырышу, башланган эшне бетерергә гайрәт итү кешенең үз җаваплылыгында. Бу эш нәтиҗәсендә ирешәчәк уңыш өчен исә Аллаһыга юнәләчәк һәм Аңа рәхмәт әйтәчәк. Кешеләр арасында шундый сүз бар: «Гайрәт - бездән, нәтиҗәсе, уңышы - Аллаһыдан».

Тәвәккәл - бер кол буларак кешенең үз мөмкинлекләрен һәм чикләрен кабул итү тотышы ул. Үз-үзеңне тану, эшли алачак яисә башкара алмаячак әйберләрне аңлау, башкара алачак эшләргә күңелеңне бирү һәм үзеңне җитештерү, камилләштерү гайрәтенә этәрүче тотыштыр. Тәвәккәл - кыю, карарлы, сабыр булу дигән сүз. «Гыймран» сүрәсенең 159 нчы аятендә бу вәзгыятькә ишарәт ителә: *«Ныклы бер карарга килсәң дә, Аллаһыга тәвәккәллә. Чөнки Аллаһы Үзенә тәвәккәлләгәннәрне сөя».* Тәвәккәл итүче кеше - бер үк вакытта башкарган эшләре белән бәйле рәвештә үз-үзенә сорау бирүче инсан. Үзе теләгән максатка, уңышка ирешә алмаган очракта кире кайтып үткәннәренә күз салучы һәм андагы кимчелекләрне күреп, аларны бетерү өчен көч сарыф итүче кеше. Тәвәккәл башкарган эшләрнең җаваплылыгын үз өстеңә алуны да тәэмин итә. Бу рәвешле үзенә һәм тормышка үпкәләүче кеше түгел, тормышта ипле, карусыз, күндәм кеше булуына да ярдәм итә.

Тәвәккәл белән бәйле күпсанлы кыйммәтләр турында әйтергә мөмкин. Болардан берсе - дога. Дога - Аллаһы белән кол арасында турыдан-туры һәм өзлексез элемтәдә булу рәвеше. Җаваплылыкны җиренә җиткерү өчен тырышучы кеше бу тырышлыкларының дога урынына китүен аңласа, нәтиҗәләрнең Аллаһы тарафыннан тормышка ашу рәхәтлеген, хозурын да хис итәр.

Тәвәккәл белән бәйләнешле тагын бер кыйммәт исә - сабыр кылу. Сабыр тәвәккәл белән бергә каралганда карарлы, чыдамлы, түземле булу, башлаган эшне бетерү кызыксынуын ахырына кадәр саклау итеп уйланырга тиеш. Ул эшне башкарганда